КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 29 март г.Казань № б-536

Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 31 декабрендәге 1441 нче карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең гомуми белем бирү оешмаларына, Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмаларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең уку-укыту пунктларына түбәндәгеләрне үткәрергә:

2021 елның апрелендә – июнендә «Тормыш иминлеге нигезләре» предметы кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең гомуми белем бирү оешмалары, Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары, уку-укыту пунктлары, «Патриот» республика яшьләрнең спорт-патриотика һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәге» дәүләт автоном учреждениесе, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ватан» хәрби-патриотика эшләре һәм хәрби хезмәткә кадәрге яшьләрне әзерләү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Патриот» хәрби-патриотика үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе, хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәкләре, яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләп бетерү муниципаль үзәкләре, яшьләр һәм балалар хәрби-патриотика иҗтимагый берләшмәләре, оборона-спорт сәламәтләндерү лагерьлары базасында, мөмкинлекләре булган муниципаль берәмлекләрдә хәрби берләшмәләр, частьләр һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгының югары белем бирүче «Казан югары танк команда Кызыл Байрак училищесы» федераль дәүләт казна хәрби белем бирү учреждениесе (алга таба – танк училищесы) базасында, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта (тулы) гомуми белем бирүче мәгариф учреждениеләрендә, башлангыч һөнәри һәм урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләрендә һәм уку-укыту пунктларында Россия

Федерациясе гражданнарына оборона өлкәсендә башлангыч белемнәр бирүне һәм аларны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләүне оештыру турындагы тәгълимнамәне раслау хакында» 2010 елның 24 февралендәге 96/134 номерлы боерыгына таянып, законнар нигезендә соңгы ике уку елында хәрби хезмәткә әзерләү күздә тотылган гражданнар (алга таба – укучылар) белән хәрби хезмәт нигезләре буенча уку-укыту җыеннарын (алга таба – Җыеннар);

2021 елның апрелендә «Патриот» республика яшьләрнең спорт-патриотика һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәге» дәүләт автоном учреждениесе базасында Татарстан Республикасы кадетлар мәктәп-интернатлары укучылары (10 нчы сыйныф егетләре) белән, танк училищесы базасында өйрәтү атулары үткәреп, биш көнлек уку-укыту Җыеннарын.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына Җыеннарны әзерләү һәм үткәрү буенча түбәндәге чараларны күрергә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына һәм «Патриот» республика яшьләрнең спорт-патриотика һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә шуларны тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта (тулы) гомуми белем бирүче мәгариф учреждениеләрендә, башлангыч һөнәри һәм урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләрендә һәм уку-укыту пунктларында Россия Федерациясе гражданнарына оборона өлкәсендә башлангыч белемнәр бирүне һәм аларны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләүне оештыру турындагы тәгълимнамәне раслау хакында» 2010 елның 24 февралендәге 96/134 номерлы боерыгы расланган Урта (тулы) гомуми белем бирүче мәгариф учреждениеләрендә, башлангыч һөнәри һәм урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләрендә һәм уку-укыту пунктларында Россия Федерациясе гражданнарына оборона өлкәсендә башлангыч белемнәр бирүне һәм аларны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләүне оештыру турындагы тәгълимнамә нигезендә Җыеннар үткәрүне оештыру;

Җыеннарның уку-укыту-методик тәэминатын оештыру;

Җыеннарны үтүгә сәламәтлеге буенча яраклы дип табылган барлык укучыларны Җыеннарга җәлеп итүне оештыру;

укучыларны Җыеннар үткәрелә торган урынга үз вакытында алып баруны һәм аннан алып кайтуны оештыру;

Җыеннарның уку-укыту программаларын үз вакытында үткәрүне һәм тулы кыйммәтле итеп үтәүне тәэмин итү;

нигезле сәбәпләр буенча Җыеннарны үтә алмаган укучылар өчен белем бирү оешмалары һәм уку-укыту пунктлары базасында материалны теоретик өйрәнү буенча өстәмә дәресләр һәм Җыеннарның уку-укыту программасы буенча сынаулар бирүне оештыру;

Җыеннарны Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында белем бирү

оешмалары, балалар һәм яшьләр өчен социаль инфраструктураның башка объектлары эше төзелешенә, эчтәлегенә һәм оештырылуына карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 3.1/2.4.3598-10 нчы санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне раслау» 2020 елның 30 июнендәге 16 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карары нигезендә оештыру.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына Җыеннарны үткәрү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрен хәрби частьләргә һәм танк училищесына беркетүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына муниципаль берәмлекләрдә Җыеннарны оештыру һәм үткәрү буенча җаваплы затларны билгеләүне; уку-укыту җыеннарын үткәрү чорында хәрби-патриотик эшләр үткәрү өчен шефлык турында килешү төзегән хәрби частьләр вәкилләрен чакыруны; «Патриот» республика яшьләрнең спорт-патриотика һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәге» дәүләт автоном учреждениесе, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ватан» хәрби-патриотика эшләре һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Патриот» хәрби-патриотика үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе, хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәкләре базасында территориаль бүленеш буенча Җыеннар оештыруны, ә хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәкләрендә уку-укыту җыеннарын үткәрү мөмкинлеге булмаган очракта, оборона-спорт сәламәтләндерү (палаткалы) лагерьлары базасында, районнарның ату урыннарындагы өйрәтү атуларын үткәреп, Җыеннар үткәрүне оештыруны;

белем бирү оешмаларына Җыеннарны 2021 елга белем бирү оешмаларының дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен үтәвенә караган акча чикләрендә финанслауны тәэмин итүне.

4. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Җыеннарны үткәрү урыннарында хокук тәртибен саклауны тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Балигъ булмаганнарның профилактик медицина тикшерүләрен үткәрү тәртибе турында» 2017 елның 10 августындагы 514н номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Балигъ булмаганнарның профилактик медицина тикшерүләрен үткәрү тәртибе турында» 2018 елның 30 гыйнварындагы 155 номерлы боерыгы нигезендә сәламәтлек саклау учреждениеләре базасында укучыларга профилактика медицина тикшерүләрен үткәрүне тәэмин итәргә;

«Патриот» республика яшьләрнең спорт-патриотика һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәге» дәүләт автоном учреждениесе, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ватан» хәрби-патриотика эшләре һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәге» муниципаль бюджет

учреждениесе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Патриот» хәрби-патриотика үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе, хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәкләре һәм оборона-сәламәтләндерү лагерьлары (палаткалы) базасында шартнамә нигезендә Җыеннар үткәрү чорына медицина хезмәткәрләре бирүне тәэмин итәргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин